**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6629**
**12.11.2018**

Башкарма комитетның «Муниципаль милектәге җир участогын даими (сроксыз) файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 31 июлендәге 4352 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 нчы карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезнамә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Муниципаль милектәге җир участогын даими (сроксыз) файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 31 июлендәге 4352 нче карарына (Башкарма комитетның 2016 елның 22 июнендәге 3185 нче, 2018 елның 14 августындагы 4576 нчы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «2013 елның 9 апрелендәге 2393 нче» сүзләрен «2016 елның 13 маендагы 2363 нче» сүзләренә алмаштырырга;

2) административ регламентта:

- 2.9 пунктының икенче баганасын түбәндәге эчтәлектәге 14.1 һәм 26 пунктчалар белән тулыландырырга:

«14.1) соратылган җир участогы тулысынча, җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән шундый җир участогыннан файдалануның максатлары нигезендә, җир участокларыннан файдалануның билгеләнгән

чикләүләре җир участогыннан файдалануга юл куймый торган территориядән файдалануның аерым шартлары булган зона чикләрендә урнашу;

26) «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ санлы Федераль законның 18 маддәсенең 4 бүлегендә каралган дәүләт мөлкәте исемлегенә яки муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән җир участогын бирү турындагы гариза белән кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты булып саналмаган зат яки аңа карата күрсәтелгән Федераль законның 14 маддәсенең 3 бүлеге нигезендә ярдәм күрсәтү мөмкин булмаган зат мөрәҗәгать итү.»;

- 3.4.2. пунктның икенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар түбәндәге срокларда гамәлгә ашырыла:

- Росреестр белгечләренә җибәрелә торган документлар (мәгълүматлар) буенча, өч эш көненнән артмаган срокта;

- башка тәэмин итүчеләр буенча – федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актларында һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында ведомствоара запроска җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары билгеләнмәгән очракта, документ яки мәгълүмат бирә торган органга яки оешмага ведомствоара запрос кергән көннән башлап биш көн эчендә.»;

- 5.1 пунктының 3 нче пунктчасындагы «каралмаган документларны» сүзләрен «тапшыру яки гамәлгә ашыру каралмаган документларны яки мәгълүматны яисә эшләрне гамәлгә ашыруны» сүзләренә алмаштырырга;

- 5.1 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 10 пунктча белән тулыландырырга:

«10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән 210-ФЗ санлы Федераль законның 7 маддәсендәге 1 бүлекнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәтүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү»;

- 5.7 пунктны түбәндәге эчтәлектәге бишенче һәм алтынчы абзацлар белән тулыландырырга:

«Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә әлеге пунктта күрсәтелгән җавапта, муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган кимчелекләрне тиз арада бетерү максатында Башкарма комитет, күпфункцияле үзәк тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм муниципаль хезмәттән файдалану максатында гариза бирүче башкарырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә әлеге пунктта күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карар

сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.»;

- 5.8 пунктны төшереп калдырырга;
- 5.9, 5.10 пунктларны 5.8, 5.9 пунктлар дип санарга.

2. Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга әлеге карарны, имзаланган көннән башлап җиде көн срокта, «Челнинские известия» газетасында бастырып чыгаруны, «Интернет» челтәрендә ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин